БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«26» 12 2018ел.** **№395**

**2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын раслау турында**

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 статьясы, 9 статьясының 11.3 өлеше нигезендә һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты **карар бирә**:

1. 2019-2020 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау программасын (кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач районы
башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Хәйретдинов